СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.10.2023 г.Лениногорск № 50

**«Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль район Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 57 номерлы карары белән расланган «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендәге муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирүе турында, шулай ук «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендәге муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирүе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль район Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 57 номерлы карары белән расланган «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендәге муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирүе турында, шулай ук «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендәге муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирүе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

16 пунктның 2 абзацында:

«яисә аларның тулы булмаган яисә дөрес булмаган белешмәләрен бирү» сүзләрен «үзләренең чыгымнары турында белешмәләр, алдан ук тулы булмаган белешмәләр бирү, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, йә күрәләтә дөрес булмаган белешмәләр бирү» сүзләренә алмаштырырга;

«йә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында алдан ук тулы булмаган яисә дөрес булмаган белешмәләр тапшырмау яисә тапшырмау» сүзләрен «яисә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләрне тапшырмау, федераль

законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, алдан ук тулы булмаган белешмәләр тапшыру, йә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru/).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Лениногорск муниципаль
районы Башлыгы,
Совет рәисе

Р.Г.Хөсәенов